№ 14 (1141), 31 март 2012 ел

Аллаһының сыйфатларын үзенә үрнәк итеп алып яшәүчеләр бу дөньяда да, ахирәттә дә котылуга ирешүчеләр. Аллаһы: *«Шөбһәсез, без аңа дөрес юлны күрсәттек. Теләсә, шөкер итүче, теләсә, хөрмәт-сыйның, яхшылыкның кадерен белмәүче булсын»*, яисә *«Кем файдалы эш эшләсә, үз файдасына, начарлык эшләсә, үзенә зарар китерә. Аллаһы, һичшиксез, колларына золым эшләүче түгел»*, дип боерып, кешене иректә калдыра. Бу хөррият тә имтихан өчен кирәкле шарт. Әгәр сайлау мөмкинлеге булмаса, фәрештәләр кебек әмер ителгәннәрдән читкә чыга алмаганга күрә, кешеләрнең сыналуларының да бер мәгънәсе булмас иде. Кешегә бирелгән акыл, фикер йөртү һәм ирадә кебек сыйфатлар аның яхшы белән начарны аера алу һәм сайлап алуларына күрә яшәү мөмкинлеге бирә. Кеше гамәлләрне сайлый, кирәкле көч сарыф итә, һәм Аллаһы да аның өчен гамәлләр барлыкка китерә. Нәтиҗәдә, башкарган барлык эшләр, гамәлләр өчен кеше үзе җаваплы. Димәк, хөррият белән җаваплылык арасында турыдан-туры бәйләнеш бар.

**Рәмзия ӘГӘ.**

*(“Иман” газетасыннан)*

# Никах һәм гаилә тормышы

**(Ахыры. Башы узган санда).**

Ир кеше көнләшүгә дә юл куймаска һәм хатынын ялгыш уйлары белән эзәрлекләмәскә тиеш. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә сәбәпсез көнләшүче ирләрдән риза түгел. Әгәр урынлы көнләшү икән, бу кирәк.

Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм кызы Фатыймадан: «Хатын-кызга иң мөһиме нәрсә?» – дип сорагач, ул: «Чит ирләрнең миңа карамавы һәм минем дә аларга күз салмавым», – дигән.

Күпләр, гаиләдә тыңлаусыз малай үстергәнче, кыз тәрбияләү җиңелрәк, диләр. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә кыз бала тәрбияләүчене бүләкләрмен, дигән. Бу хакта хәдистә: *«Әгәр кыз бала дөрес юлда тәрбияләнсә, кыямәт көнне әтисенең баштa уң ягына, аннан сул ягына басып, аны җәһәннәм утыннан саклый. Әгәр иманлы ике кыз бала тәрбияләсә, алар аны җәннәткә озатырлар»*, – диелә.

Гаиләдә, ир белән хатын бер-берсен ничек кенә яратмасын, үпкәләүсез, тавышсыз булмый. Чөнки адәм баласы иң камиле түгел. Әгәр сүзгә киләсез икән, икегезнең берегез дуслашу юлына басыгыз. Бу саваплы юл булыр.

Бервакыт Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе Гомәр ике ирне талашкан гаиләне дуслаштырырга җибәргән. Әмма алар тиешле нәтиҗәгә ирешмичә кайта. Шуннан Гомәр камыш алып аларга суга һәм: «Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә ике кеше татулашуны теләсә, мин ярдәм итәрмен», – дигән һәм аларны кире җибәргән. Икенче тапкыр барганда алар максатларына ирешкән.

Әгәр хатын-кыз ирен тыңламый икән, көчле зат аны буйсындырырга тиеш. Әгәр хатын-кыз намазларын калдыра икән, ул аны намаз укырга мәҗбүр итсен. Әмма һәр гамәлнең чиге бар. Башта ир хатынына матур итеп, вәгазьләп аңлатырга, әгәр сөйләшүнең файдасы булмаса, 2-3 көн аерым йокларга тиеш. Алай да нәтиҗәсе булмаса, шәригать кушканча җәза бирергә, куркытырга ярый, ләкин көч куллану тыела. Әмма ир кеше 20-30 көннән соң да максатына ирешә алмаса, аерылышырга мөмкин.

Ир хатынның намаз укымый торган көннәрен, аңа нәрсә ярый, нәрсә ярамаганлыгын белергә тиеш. Шәригать ирләргә хатыннарын тәмугтан саклауны бурыч итеп куя. Коръәндә дә: *«Үзегезне һәм гаиләгезне җәһәннәм утыннан саклагыз»*, – диелә.

Ир хатынына ислам диненең сөннәтен аңлатырга һәм шәригать кушканча үтелмәгән юлның азагын күрсәтергә тиеш.

Әгәр ир хатынын мөһим кагыйдәләргә өйрәтә икән, аңа каядыр кинәш сорап гыйлемле мөселманнарга бару да кирәкми. Әгәр ир үзе белми икән, хатынын гыйлем алудан тыярга тиеш түгел! Ә инде ир дә өйрәнми, хатыны да белми икән, икесе дә гөнаһлы булалар.

**Сәрия ЗАКИРОВА.**

*(«Дин вә йола» газетасыннан)*

# Ихлас намаз – тәүбә ул

Намаз кешеләрне стресстан, рухый төшенкелектән, гөнаһлардан коткара, көндәлек тормышыбызны билгеле бер тәртиптә алып барырга ярдәм итә. Кәгъбә аркылы кешеләрне Аллаһы Тәгалә белән катнаштыра, кыямәт көнендә җәзалардан азат итә, ягъни намаз мөэмин-мөселман хәятында бик әһәмиятле урын тота. Намазны елга, айга, атнага биш тапкыр түгел, ә һәр көнне биш тапкыр кылган вакытта гына аның нинди зур көчкә ия булуын, асылын аңлый башлыйлар. Намаз ул бары тик төрле-төрле хәрәкәтләр ясау гына түгел, ә ихлас күңелдән булырга тиеш.

Рәсүлебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм безгә түбәндәгеләрне әйтеп калдырган: *«Әгәр кеше тәһарәтен дөрес, шартына китереп алса, күңеле белән, йөзе белән Аллаһыга юнәлеп намаз укыса, ул, һичшиксез, җәннәткә керер»*.





*Тел белән намаз укыйсың*
*Һәм кыласың тәүбәне.*
*Чын мөселман шул ясый бит,*
*Рәнҗетмәсәң бәндәне.*

*Тел кәфер ясый адәмне,*
*Вәт шуңа дошман, диләр.*
*“Телне сакларга тиеш”, - дип*
*Пәйгамбәр әйткән, диләр.*

*Аның сүзе безгә сөннәт,*
*Без тотаек сөннәтен.*
*Сакласын Аллаһ кәфердән*
*Бер Мөхәммәт өммәтен.*
*Шул теләктә мин тәмамлыйм,*
*Кабул кылсын Ходаем.*
*Изге теләкләр теләшик*
*Көн саен, җомга саен.*

*Бергәләшеп без теләсәк,*
*Бер Ходаем ярлыкар.*
*Минем өчен дә теләгез,*
*Булмасын, дип, кабере тар.*

**Гайниҗамал ГЫЙСМӘТУЛЛИНА.**

# Хикмәтле сүзләр

**Хөрмәтле редакция хезмәткәрләре! “Кыйбла” кушымтасында шушы үгет-нәсыйхәтләрне бастырып чыгарсагыз иде. Бу кешеләргә бик тә файдалы булыр, дип уйлыйм. Биредәге хикмәтле сүзләр, бәлки, күпләргә туры юл күрсәтер, күпләргә гыйбрәт булыр, күпләрне тормыш кыйммәтләре турында уйланырга мәҗбүр итәр.**

**Мәрьям ИМАНГОЛОВА.**
Сукай авылы,
Похвистнево районы.

Аллаһының колы бул, Аңа һичнинди ширек катнаштырма (Ходайның улы яисә берничә Аллаһы бар дип).

Гамәлеңне үтәгәндә Аллаһыны күреп торгандай бул, үзеңне үлгән, дип исәплә.

Һәрбер таш һәм агач янында Аллаһы Тәгаләне исеңә төшер (боларның барысын да Аллаһы Тәгалә яраткан бит дип).

Бер гөнаһлы эш башкаргансың икән, артыннан ук изгелек кыл.

Берәрсен рәнҗеткәнсең икән, догасыннан саклан (курык), чөнки ул кабул булачак.

Галим, йә белем алучы, йә галимнәр сүзенә колак салучы, йә аларга мәхәббәтле бул, әмма бишенчесе (каршы) булма, һәлак булырсың.

Мөселман кеше белем алып, белгәнен дин кардәшенә өйрәтсә, шул садаканың иң яхшысы булыр.

Кыямәт көнендә иң күп гөнаһлы кешеләр — иң күп мәгънәсез сүз сөйләүчеләр. Телнең иң зур хатасы — ялган.

Иң зур байлык — күңел байлыгы.

Хикмәт башы — Аллаһыдан курку.

Байлык тоту — утта кыздырып басылган мөһер.

Иң яман ризык — ятимнәр малы.

Бәхетле кеше — башкаларга карап гыйбрәт алучы.

Һәммәбезнең урыны — дүрт аршин җир (кабер).

Берәү ачуын басса, Аллаһы Тәгалә аңа шуның әҗерен бирер.

Берәү түземле булса, Аллаһы Тәгалә аңа икеләтә әҗерен бирер.

Аллаһы Тәгалә алдында күп бала тудырган хатын бала тудырмаган чибәр хатыннардан сөеклерәк.




**- Кайбер авылларда мәетнең баш очына утырып, 2 кеше китаптан 41 мәртәбә “Тәбарәк” укый. Дөресме?**

- Мәет өчен догалар уку кайда ничек гадәткә кергән, шулай эшлиләр. Ләкин ул нәкъ шулай эшләгез, дигән сүз түгел. Шәригатьтә андый сүз юк. Мәетне юганчы укысалар, аның баш очында түгел, икенче бүлмәдә генә укырга ярый. Югач исә «Тәбарәк»не 41 тапкыр уку мөмкин түгел, чөнки аңа берничә сәгать вакыт кирәк.

**- Коръән укып, әрвахларга багышлаганда, иң элек пәйгамбәрләрнең рух-шәрифләренә багышлыйбыз. Аннан әти-әниләргә, туганнарга. Ул вакытта да: рух-шәрифләренә, дип багышларгамы, әллә рухларына гына дияргәме? Рух-шәриф нәрсә ул?**

- Рух - җан, шәриф - кадерләүгә, хөрмәтләүгә лаек зат дигәнне аңлата. Пәйгамбәрләрнең рух-шәрифенә дип багышлау дөрес. Ә алардан кала башка бәндәләргә рух-шәрифенә дип багышларга ярамый, дигән сүзләр бар. Шуңа күрә рухына, дип кенә багышлагыз.

*(“Татар мөселман календаре”ннан)*